

«Известия Мордовии»га Эрьзя музее директоры Людмила Нарбекова сойлəгəнчə, «Федот Сычков – шатлык рəссамы» кvргəзмəсен Пензада бер ел элек, якташыбыз, уникаль рəссамнын 150 еллыгына багышлап кvрсəтергə ниятлəнгəн булган. Остəвенə, пензалылар vзлəре дə рəс-самнын əсəрлəрен кvрсəтергə телəк белдергəннəр. Бу анлашыла да, чонки кvрше олкəдə яшəvчелəр Сычковны vз якташлары дип саный алар. Эш шунда ки, рəссам туган Кочелай авылы элек Пенза губернасынын Наровчат оязенə караган.       Моннан тыш, 1918 елда Сычков хезмəттəше белəн Октябрь революциясе еллыгына багышланган бəйрəм бизəлешен булдыру һəм Пенза губернасында беренче сəнгать кvргəзмəсен оештыру белəн шогыльлəнə. Ə тагын, булган мəгълvматларга караганда, ул этюдларны Пенза янындагы Император сəнгать академиясе буенча хезмəттəше һəм сыйныфташы Иван Горюшкин-Сорокопудов дачасында язган. Əмма пандемия аркасында юбилей кvргəзмəсен кичектергəн булганнар. Тик менə хəзер, 30 июльдə ул, ниһаять, Пенза олкə картиналар галереясендə ачылды. Тамашачылар игътибарына Эрьзя музее жыелмасыннан Федот Сычковнын кырык əсəре тəкъдим ителде. Сентябрь ахырына кадəр Пензада кvренəчəк.
Пенза картиналар галерея-се директоры Кирилл Застрожный кунакларны сə-ламлəп, нəтижəле музей хезмəттəшлегенен активлашуын канəгатьлек белəн билге-лəп vтте. Беренче кvргəзмəдə Пенза олкəсенен мəдəният һəм туризм министры Татьяна Курдова да булды.
Вернисажга килгəн һəркем очен аерым сюрприз булып жирле мордва фольклор коллективынын чыгышы булды, ул кvргəзмə кинлеклəре атмосферасын милли тослəр белəн тулыландырды.
Сvз унаенда, юбилей экспозициясенə кертелгəн эшлəрнен кvбесе музей запасникларында саклана һəм тамашачыларга сирəк кvрсəтелə.

**Н.ХƏЛИЛ əзерлəде**